ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　КАРАР

09　09　2022 г. № 223

Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2008 елның 22 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре территориясендә алып ташлана торган (киселә торган) яшел утыртмаларның бәясен исәпләү методикасына һәм компенсацион яшелләндерү үткә-рүгә үзгәрешләр кертү турында

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 78 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 2022 елның 7 июлендәге 02-06-2022/Прдп212-22-20000205 номерлы протестын үтәү йөзеннән, Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2008 елның 22 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре территориясендә алып ташлана торган (киселә торган) яшел утыртмаларның бәясен исәпләү методикасына һәм компенсацион яшелләндерү үткәрүгә кертелә торган кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Түбән Кама муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә (Енькова Я.С.) әлеге карарны матбугат басмаларында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
Җитәкче урынбасары　　　　　　　　　А.А. Ярмиев

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044881

Татарстан Республикасы
Түбән Кама шәһәре
башкарма комитетының
2022 елның «09» 09
223 номерлы карарына
кушымта

Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2008 елның 22 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре территориясендә алып ташлана торган (киселә торган) яшел утыртмаларның бәясен исәпләү методикасына һәм компенсацион яшелләндерү үткәрүгә кертелә торган үзгәрешләр

1. 1 статьяда:

1.1 пунктында «Урман законнарын бозу аркасында урманнарга китерелгән зыян күләмен исәпләү турында» 2007 елның 8 маендагы 273 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән» сүзләрен «Урман законнарын бозу аркасында урманнарга һәм аларда булган табигый объектларга китерелгән зыянны каплау үзенчәлекләрен раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1730 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктының өченче абзацын төшереп калдырырга.

2. 2 статьяда:

2.1. пунктының беренче абзацында «үсемлекләр» сүзен «яшел утыртмалар» сүзләренә алыштырырга;

2.2. пунктында:

беренче абзацта «Үсемлекләргә китерелгән зыян күләмен билгеләгәндә» сүзләрен «Яшел утыртмаларны алып ташлаган (кискән) өчен түләү күләмен исәпләгәндә» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «Үсемлекләргә китерелгән зыянны каплау» сүзләрен «Яшел утыртмаларны алып ташлаган (кискән) өчен түләү» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктында:

беренче абзацта «Агач-куак, үлән үсемлекләренә китерелгән зыянның (зарарның) күләмен билгеләгәндә» сүзләрен «Яшел утыртмаларны алып ташлаган (кискән) өчен түләү күләмен исәпләгәндә» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «зарарланган, юкка чыгарылган» сүзләрен төшереп калдырырга, «үсемлекләр» сүзен «яшел утыртмалар» сүзләренә алыштырырга;

тугызынчы абзацны төшереп калдырырга;

2.4 пунктында:

беренче абзацта «Яшел утыртмаларны алганда зыян (зарар) күләме формулалар буенча билгеләнә» сүзләрен «Яшел утыртмаларны алып ташлаган (кискән) өчен түләү күләме формулалар буенча билгеләнә» сүзләренә алмаштырырга;

таблицаның өченче баганасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яшел утыртмаларны алып ташлаган (кискән) өчен түләү күләмен исәпләү формуласы*»;

Таблицаның дүртенче баганасындагы 1, 2, 3, 4 юлларда беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Y - түләү күләме»,

таблицаның дүртенче баганасының 1 юлында унберенче абзацны төшереп калдырырга;

таблицаның дүртенче баганасының 2,3 юлында сигезенче абзацны төшереп калдырырга;

таблицаның дүртенче баганасының 4 юлында алтынчы абзацны төшереп калдырырга;

таблицага искәрмәдә «*Яшел утыртмаларны алганда зыян (зарар) күләме» сүзләрен «*Яшел утыртмаларны алып ташлаган (кискән) өчен түләү күләме» сүзләренә алмаштырырга;

1 нче таблицаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Агач үсемлекләрен алып ташлау (кисү) өчен түләү күләмен билгеләү күрсәткечләре»;

2 нче таблицаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Куак һәм үлән үсемлекләрен алып ташлау (кисү) өчен түләү күләмен билгеләү күрсәткечләре»;

6 нчы таблицаны төшереп калдырырга.

3. 3 статьяның 3.2. пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Урман утыртмаларына яки урман утыртмаларына кертелмәгән агачларга, куакларга һәм лианаларга законсыз зыян китерү яки юк итү нәтиҗәсендә китерелгән зарар «Урман законнарын бозу аркасында урманнарга һәм аларда булган табигый объектларга китерелгән зыянны каплау үзенчәлекләрен раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1730 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган такса һәм методика нигезендә исәпләнә».